ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 пунктында «Пенсионерларга» сүзеннән соң «60 һәм 55 яшьләргә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән затларга» сүзләрен өстәргә;

2) 8 статьяның 7 пунктындагы беренче абзацында «күләменнән түбәнрәк» сүзләреннән соң «һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе әлеге Законга кушымтада билгеләнгән дәрәҗәдән кимрәк» сүзләрен өстәргә;

3) түбәндәге эчтәлекле кушымта өстәргә:

«“Татарстан Республикасында
халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү
турында” Татарстан Республикасы
Законына кушымта

## Гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе

Гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе дигәндә гаилә әгъзалары (граждан) милкендә түбәндәге пунктларның берсендә яисә берничәсендә күрсәтелгән мөлкәт булу аңлашыла:

а) мәйданы гаиләнең һәрбер әгъзасына исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артыграк туры килә торган, Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле торак урын (торак урынның өлеше). Торак урын мәйданын исәпләгәндә гаиләнең Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлеккә кертелгән авыр хроник авырудан интегүче әгъзасы били торган торак урын мәйданы (шул исәптән фатирдагы аерым бүлеп алынган торак урын мәйданы), мондый авырудан интегүче зат белән бергә яшәү законнар нигезендә мөмкин булмаганда, шулай ук билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын исәпкә алынмый;

б) кушып исәпләнгән мәйданы ялгыз яшәүче гражданга исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артыграк, ә ике һәм аннан күбрәк кешедән торган гаиләгә исәпләгәндә гаиләнең һәрбер әгъзасына 23 квадрат метрдан артыграк туры килә торган, Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле ике һәм аннан күбрәк торак урын (торак урыннарның өлешләре). Торак урыннар мәйданын исәпләгәндә гаиләнең Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлеккә кертелгән авыр хроник авырудан интегүче әгъзасы били торган торак урын мәйданы (шул исәптән фатирдагы аерым бүлеп алынган торак урын мәйданы), мондый авырудан интегүче зат белән бергә яшәү законнар нигезендә мөмкин булмаганда, шулай ук билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын исәпкә алынмый;

в) Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле һәм торак урын булып саналмый торган бина, төзелмә, корылма (бинаның, төзелмәнең, корылманың өлешләре) (моңа транспорт чараларын кую өчен билгеләнгән күчемсез мөлкәт объектлары (гараж, машина урыны), индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә, бакча җир кишәрлекләрендә урнашкан каралтылар, шулай ук әлеге кушымтаның «г» пунктында санап кителгән объектлар керми);

г) кушып исәпләнгән мәйданы гаиләнең бер әгъзасына исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артыграк туры килә торган, каралты булып саналмый торган Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле бер яисә берничә бакча өе, дача (бакча) төзелеше объектлары;

д) мәйданы (кушып исәпләнгән мәйданы) гаиләнең бер әгъзасына исәпләгәндә 0,2 гектардан артыграк туры килә торган Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле бер яисә берничә җир кишәрлеге;

е) Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынган автомобиль, автобус, үзйөрешле машина, пневматик һәм чылбырлы механизм, самолет, вертолет, теплоход, яхта, җилкәнле судно, катер, кар чанасы, моточана, гидроцикл, буксир ярдәмендә хәрәкәтләнә торган үзйөрешле булмаган судно, башка су һәм һава транспорты чарасы (моңа җиңел автомобиль, шулай ук биштән күбрәк урынлы һәм дүрт яки аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләгә бирелгән (сатып алынган) автомобиль керми);

ж) берсенең эшләп чыгарылган елы мөрәҗәгать итү көненә өч елдан артмаган ике һәм аннан күбрәк җиңел автомобиль (моңа инвалид идарә итү өчен махсус җайланмасы булган җиңел автомобиль, биштән күбрәк урынлы һәм дүрт яки аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләгә бирелгән (сатып алынган) автомобиль керми).».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан тыш, 2019 елның 1 апреленнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2019 елның 1 гыйнварыннан, ләкин рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көннән дә иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 20 декабрь
№ 107-ТРЗ